**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 4 июнендәге 1665 номерлы карары**

**Яшь гаиләләрнең түли алу мөмкинлеген исәпләү өчен**
**2025 елның икенче кварталына Казан шәһәрендә гомуми торак**
**мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын**
**билгеләү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы «“Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында»гы карарын гамәлгә ашыру максатыннан, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 21 мартындагы 172/пр номерлы «2025 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе турында»гы әмерен исәпкә алып **карар бирәм**:

1. Яшь гаиләләрнең түли алу мөмкинлеген исәпләү өчен 2025 елның икенче кварталына Казан шәһәрендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын 151 747 сум дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**